БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ**
17 декабрь 2019 ел

**КАРАР**
№ 220

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл жирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр бирү Кагыйдәләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр бирү Кагыйдәләрен кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап, бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәлгәндә барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе

Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2019 елның 17 декабрендәге
220 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр бирү Кагыйдәләре

1. Әлеге кагыйдәләр Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны башкару вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр (алга таба – субвенцияләр, җирлекләр) бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Субвенцияләр хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен үтәү максатларында җирлекләр бюджетларына бирелә.

3. Җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бирү чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетына бирелә торган хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан субвенция тора.

4. Әлеге Кагыйдәләр нигезендә бирелә торган бюджет акчаларының баш бүлүчесе булып Татарстан Республикасының Балтач район башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тора.

5. Җирлек бюджетына субвенция күләме «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 11 декабрендәге 78-ТРЗ номерлы Законга 1 нче кушымтада каралганча муниципаль район бюджетыннан җирлек бюджетына субвенция күләмен билгеләү методикасы нигезендә билгеләнә.

6. Муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләрне бүлү Татарстан Республикасы Балтач район Советының тиешле финанс елына һәм план чорына муниципаль район бюджеты турындагы карары белән раслана.

7. Субвенцияләр тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм Башкарма комитетка билгеләнгән тәртиптә әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында каралган максатларга бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җирлекләр бюджетларына бирелә.

8. Субвенцияләр җирлекләр бюджетларына түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен бирелә:

хезмәткә түләү фондына тиешле түләүләрне дә кертеп, хәрби-учет хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү;

биналарны арендалау өчен түләү;

элемтә хезмәтләре өчен түләү;

транспорт хезмәтләре өчен түләү;

командировка чыгымнары;

коммуналь хезмәтләр өчен түләү;

җиһаз, инвентарь, оргтехника, элемтә чаралары, чыгым материаллары белән тәэмин итү.

9. Субвенцияләрне тоту җирлекләр бюджетларын үтәүгә касса хезмәте күрсәтү өчен ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнарының (алга таба – Казначылык) шәхси счетлары аша башкарыла.

10. Башкарма комитет казначылыктан финанслауның иң чик күләмнәрен билгеләү өчен чыгым расписаниесен алганнан соң җиде эш көне эчендә Казначылыкка субвенцияләр исәбеннән җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күчерү өчен касса чыгымына гариза бирә.

11. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнары квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән килештереп, субвенция финанс тәэмин итү чыганагы булган хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен үтәүгә бәйле җирлекләр бюджетларының чыгымнары Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча хисапны тапшыра.

12. Башкарма комитетка тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеге өчен җаваплылык җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

13. Субвенцияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә муниципаль район бюджеты кеременә күчерелергә тиеш.

14. Субвенцияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына субвенцияләрнең файдаланылмый калган өлеше, Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә, муниципаль район бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

15. Субвенцияләр максатчан характерга ия һәм, әлеге Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгәннәрдән тыш, башка максатларда кулланыла алмый.

16. Субвенцияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тотуны законнар нигезендә Башкарма комитет һәм муниципаль районның финанс органы башкара.